## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

26.03.2024 ел № 4

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 мартындагы «2023 елның 4 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 47 санлы, 2023 елның 4 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 48 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 4 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2023 елның 4 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 47 санлы, 2023 елның 4 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 48 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бәйрәкә торак пунктында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзү: вак таш, асфальт сатып алу, нигезне әзерләү);

- Бәйрәкә торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техника арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Бәйрәкә торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннарын (парк) һәм аларга якын урнашкан территорияләрне төзекләндерү);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны

чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктта яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү Бәйрәкә торак пунктында (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Бәйрәкә торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (каберлек территориясендә карт агачларны кисү, агачларны химик эшкәртү (химик препаратлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- торак пунктның урам яктырту җайланмасы урнаштыру (Бәйрәкә торак пунктында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуына хезмәт күрсәтү);

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләрен) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Бәйрәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (peep//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина